| СОВЕТ<br>Девятернинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Девәтернә авыл җирлеге<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2018 Девәтернә авылы № 46-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында " 2017 елның 20 ноябрендәге 32-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законы, Девәтернә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 ноябрендәге 32-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, яки Девәтернә авыл җирлеге Советы карарлары нигезендә инновацион һәм инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен төзелгән сәнәгать паркы урнаштырылган җир өлешләренә карата **0,9%** ;»

6 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«6. Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү узган хисап чорыннан соң беренче, икенче һәм өченче кварталдан соң килә торган айның беренче числосыннан да соңга калмыйча җир өлешләренең кадастр бәясе процент өлешенең тиешле салым ставкасына ¼ өлеше күләмендә туры килә торган аванс түләүләре белән башкарыла".

2. Әлеге карарны Девәтернә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына куярга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтына agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталына pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының Финанс-бюджет, социаль законлылык һәм хокук тәртибе комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе Ф.М. Юсупов